БАЛАЛАР ЖУРНАЛЫ • ДЕТСКИЙ ЖУРНАЛ • CHILDREN'S MAGAZINE

№12.2016

Салават күпере

0+

ISSN 0868-4545



№12 (321) – 2016

Журнал 1990 елның март аеннан бирле чыга. Журнал выходит с марта 1990 года.

Директор
Зиннур ХӨСНИЯР (Зиннур Зыятдин улы ХӨСНЕТДИНОВ)

Баш мөхәррир
Зилә ЯЗ (Зилә Зиннур кызы ХӨСНЕТДИНОВА)

Баш мөхәррир урынбасары
Гүзәл ЗИННӘТУЛЛИНА

Мөхәррирләр
Гөлназ ЯРМИЕВА
Алсу НИЗАМИЕВА

Баш рәссам
Әлфия ЙОСЫПОВА

Компьютер дизайны
Мөнирә КУЗИЕВА

0+ Мәктәпкәчә яшьтәге һәм кече яшьтәге мәктәп балалары өчен.

«Салават күпере» журналының компьютер үзәгендә җыелды һәм төсләргә бүленде.

Басарга кул куелды 22.11.16 ел.
Кәгазь форматы 60х90 1/8.
Гарнитура – PT Sans.
Офсет ысулы белән басыла.
Заказ: М-3046. Тираж: 8700 данә.

Килгән хатлар, кулъязмалар һәм рәсемнәр рецензияләнми, авторларга кире кайтарылмый.

Почта гаебе белән журнал өегезгә килеп җитмәсә, түбәндәге телефон белән газета-журналлар экспедициясенә шалтырата аласыз: (843) 562-10-66.

Журналны гамәлгә куючы – «ТАТМЕДИА» АҖ.

Татарстан республикасы матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәмендә чыгарыла.

Бәясе ирекле.
ЯЗЫЛУ ИНДЕКСЫ:
Татарстанда – П2339
Россиядә – 73953.

Тышлыкта Эрик Зиазов рәсеме, Казан, 5 нче гимназия.

Нәшер итүче: «ТАТМЕДИА» АҖ, 420097, Казан, Академическая ур., 2 й.
Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2 й., 10 кат.
Тел.: (843) 222-05-46.
E-mail: salavatkupere@mail.ru
Сайт: www.salavatkupere.com

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча федераль хезмәт тарафыннан ФС77-54277 номеры белән 2013 елның 24 маенда теркәлде.

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2 й.

2017 ЕЛГА КАЛЕНДАРЬ

Календарьны кисеп алып, пунктир буенча бөклә, ак өлешләрне ябыштыр. Ул пирамида рәвешен алырга тиеш. Эшләнмәнең очына җеп беркетсәң, аны чыршы уенчыгы итеп тә куллана аласың.



© «Салават күпере», 2016 ел.

ЯЗЫЛЫРГА АШЫК!

«САЛАВАТ КҮПЕРЕ» ЖУРНАЛЫНА ҺӘР АЙДАН ЯЗЫЛЫП БУЛА. БҮГЕНГЕ КӨНДӘ 2017 ЕЛНЫҢ БЕРЕНЧЕ ЯРТЫЕЛЛЫГЫНА ЯЗЫЛУ БАРА. ДИМӘК, НИБАРЫ 254 СУМГА НӘНИЕГЕЗ 6 АЙ БУЕ (ГЫЙНВАРДАН ИЮНЬГӘ КАДӘР) КЫЗЫКЛЫ ҺӘМ УЕНЧЫКЛЫ «САЛАВАТ КҮПЕРЕ»Н АЛЫП ШАТЛАНАЧАК.

Кадерле балалар,
хөрмәтле әти-әниләр!
Барыгызны да якынлашып килүче Яңа 2017 ел белән котлыйм!

Балакайлар, мин сезгә күп итеп бүләкләр әзерләп куйдым! Ләкин аларны Яңа елга кадәр таратып бетерә алмам дип куркам. Шуңа кайберләрен «Салават күпере» журналында эшләүче абый-апаларга биреп калдырдым! Әгәр әти-әниегез журналга язылса, үзегез бәйгеләрдә катнашсагыз, бүләк һичшиксез сезнеке булачак! Журналга язылырга ашыгыгыз!
Очрашканга кадәр!

Кыш Бабай



• «ПОЧТА РОССИИ»НЕҢ «ПОДПИСНЫЕ ИЗДАНИЯ» (ПАП) РӘСМИ КАТАЛОГЫ БУЕНЧА ЖУРНАЛЫБЫЗНЫҢ ЯҢА ИНДЕКСЫ: П2339.


• ТАТАРСТАННАН ЧИТТӘ ЯШӘҮЧЕЛӘР «РОСПЕЧАТЬ» КАТАЛОГЫНДАГЫ ЭЛЕККЕГЕ ИНДЕКС БУЕНЧА ЯЗЫЛА АЛА: 73953.

• ШУЛАЙ УК WWW.USLUGI.TATARSTAN.RU ПОРТАЛЫ АША ЭЛЕКТРОН ЯЗЫЛУ МӨМКИНЛЕГЕ БАР. ШӘХСИ КАБИНЕТЫГЫЗГА ЯЗЫЛУ ТЕРКӘЛГӘН ДИГӘН ХӘБӘР КИЛӘ, ҺӘМ СЕЗ БИЛГЕЛӘГӘН ВАКЫТТАН ЖУРНАЛ ӨЕГЕЗГӘ КИЛЕП ҖИТӘЧӘК.

• PRESSA.RU ЯКИ TATPODPISKA.RU САЙТЛАРЫ АША ЯЗЫЛСАГЫЗ, ТЕРКӘЛГӘН ВАКЫТТА ЯЗЫП КАЛДЫРГАН ЭЛЕКТРОН АДРЕСКА ЖУРНАЛ PDF-ФОРМАТЫНДА КИЛӘЧӘК.

• АЛЬТЕРНАТИВ ЫСУЛ КАЗАН ШӘҺӘРЕНДӘГЕ БАЛАЛАР БАКЧАЛАРЫ ҺӘМ МӘКТӘПЛӘР ӨЧЕН КУЛАЙ. ЖУРНАЛНЫ АЙ САЕН ҮЗЕБЕЗ АРЗАНРАК БӘЯГӘ КИТЕРЕП БИРӘБЕЗ! ТЕЛЕФОН: (843) 222-05-46.

ФИЛИАЛ №4



Танылган әдип, шагыйрь, прозаик һәм драматург Марсель Баян улы Галиев 1946 елның 8 октябрендә Татарстан Республикасының Азнакай районы Балтач авылында туа. Мәктәп елларыннан соң бер ел Азнакайдагы төзелеш оешмасында рәссам-бизәүче булып эшли. Аннары армиягә алына һәм берьеллык хәрби мәктәпне бетерә.


М.Галиев 1969 елда Казан дәүләт университетының журналистика факультетына укырга керә. Укуын тәмамлагач, Татарстан Язучылар берлегендә эшли, «Казан утлары» журналының проза бүлеген җитәкли.

Марсель абый Галиев күбесенчә поэзия һәм проза жанрларында иҗат итә. Аның беренче шигырьләре 1970 елда яшь шагыйрьләрнең күмәк җыентыгына кертелә, соңрак «Еллар чалымы» дигән шигырьләр җыентыгы, ә 1980 елда повесть һәм хикәяләрдән торган «Ул чакта» исемле проза китабы дөнья күрә.

М.Галиевнең юмор-сатира, драматургия, әдәби тәрҗемә һәм җыр текстлары иҗат итү өлкәләрендә дә уңышлары бар. Аның аерым әсәрләре рус, поляк, украин, үзбәк, казакъ, каракалпак, осетин, чуаш телләренә тәрҗемә ителә. Марсель абыйның балалар өчен чыгарылган «Ак рәсем», «Шүрәле һәм җил», «Җиңәсем килде» китаплары яратылып укыла.

1993 елдан М.Галиев «Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем йөртә. 2006 елда ул Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була.

«Салават күпере» журналханәсе Марсель абый Галиевны ихластан юбилее белән котлый!



Рәссам Әлфия ЙОСЫПОВА

КӨЗГЕ КАРШЫНДА

Үзен күргәч тә көзгедә
песи аптырап калды.
Борынга борын тидереп
иснәшеп тә карады.
Әмма таныш түгел песи
горур иде, шук иде,
көзгедән килеп чыгарга
исәбе дә юк иде.
Шуннан песи аны эзләп
көзге артына чыкты,
аннан да таба алмагач,
мыеклы йөзен чытты.
Көзгедәге песине ул
бик ошатты – аңладым.
Песи телен белмәгәч мин:
«Көзгедә дә син үзең бит», –
дип аңлата алмадым.

ПЕРЕД ЗЕРКАЛОМ

Кот перед зеркалом сидел,
впервые в зеркало глядел.
Был отраженьем удивлён –
его сперва обнюхал он.
А тот, кто в зеркале сидел –
на моего кота смотрел,
был тоже чем-то удивлён,
но выходить не думал он.
Вот призадумался мой кот:
«Где незнакомец тот живёт?»
За зеркало решил зайти,
но там не смог его найти.
И мой любимец загрустил,
усы до полу опустил:
ему понравиться успел
тот, кто из зеркала смотрел.
Если б знал язык кошачий,
объяснить коту бы смог:
«Улыбнись! Себя ты видишь
в этом зеркале, дружок!»

Перевод Талии ШАРАФИЕВОЙ

FACING A MIRROR

Upon seeing a stranger in the mirror,
My cat bravely wrestled his fear,
He gently sniffed the kitten he found:
There was no smell, even no sound.
The guest responded to the greeting,
Looking surprised as well, no doubt.
But the unknown wide-eyed kitten
Had no intention to come out.
My curious cat checked the reflection
Nervously trying to reach out –
There was no response, no objection,
He stared at the guest and frowned.
The cat was puzzled by the creature
Looking at him from the mirror,
But there's no language to teach him:
'It is yourself you see, my dear!'

Translation Dilyara Sharifullina

КАР БӨРТЕГЕ МАЛАЕ

Әкият

Яшәгән, ди, кечкенә кар бөртеге малае. Ул бик шаян булган. Әнисенең әйткәнен гел тыңламаган.

Менә бер матур көнне ул башка кар бөртекләре белән уйнарга чыгарга теләгән. Әнисе аңа:


– Улым, сак бул, кешеләрнең өсләренә кунма! Алар җылы өйләренә кергәч, эреп бетәрсең, суга әйләнерсең, – дигән. Кар бөртеге малае әнисен тыңлап та бетермәгән, уйнарга чыгып йөгергән.

Алар башка кар бөртекләре белән туйганчы уйнаганнар: очканнар, бөтерелгәннәр, куышканнар, балаларның өсләренә дә кунаклаганнар. Безнең шаян кар бөртеге Азат исемле малайның бүрегенә ябышкан. Шул вакыт Азатны әнисе өйгә чакырган. Азат йөгереп өйгә кергән. Кар бөртегенең җылыдан хәле беткән, башы әйләнгән. Әнисенең сүзләре исенә төшкән. Азатның әнисе:

– Улым, өстеңнән кар бөртекләрен кагып кер, эреп бетәләр бит, – дигән. Азат әнисен тыңлый торган тәртипле малай булган. Ул тиз генә өс-башын кагып кергән. Шаян кар бөртеге хәлсезләнеп җиргә төшкән. Шул вакыт әнисе аңа ярдәмгә килгән. Әниләрнең сүзен тыңларга кирәклеген безнең шаян кар бөртеге шунда аңлаган.

Зинфира Равис кызы ГАРИФУЛЛИНА, Минзәлә, Исәнгол.
«Багалмам» бәйгесенең «Балалар өчен иң яхшы әкият» номинациясе җиңүчесе.

ӘЛЕГЕ ҮРНӘК БУЕНЧА КАР БӨРТЕКЛӘРЕ ЯСАП КАРА.





Калыплардагы бизәкне әзер җирлеккә (4 нче рәсем) ясап, зәңгәр өлешләрен кисеп ал.



ШАКМАКЛАРНЫ КҮРСӘТЕЛГӘН САННАР БУЕНЧА УКЛАР ЮНӘЛЕШЕНДӘ БУЯ. НИНДИ РӘСЕМ КИЛЕП ЧЫГАР?



СИНЕҢ РӘСЕМНӘРЕҢНЕ ДӘ КӨТЕП КАЛАБЫЗ!



*Алия ГАЯЗОВА,
Казан,
3 нче сыйныф.*



*Әлфинур ХӘЙРУЛЛИНА,
Казан,
3 нче сыйныф.*



*Зәмирә ГАЛИЕВА,
6 яшь.*



*Ангелина ВОЛКОВА,
Казан, 33 нче мәктәп,
4 нче сыйныф.*



*Лилия АБДУШАЕВА,
Казан, 5 нче гимназия,
7 нче сыйныф.*



*Әдилә ГАРИПОВА, Казан,
5 нче гимназия,
2 нче сыйныф.*



*Язилә,
Казан, 6 яшь.*



*Мәрьям ФӘЙЗРАХМАНОВА,
Казан,
3 нче сыйныф.*



*Рәмзия КАВИЕВА,
3 нче сыйныф.*



Сказка про настоящих друзей



В маленькой деревушке жил-был котёнок по имени Тина. Как-то он пошёл к одному своему другу, которого звали Отвит. Затем они пошли к другому другу, которого звали Хин. И начали вместе играть. Котята очень любили играть с клубочком. Через два часа они захотели кушать и вернулись домой. Дома они попили молоко. Затем снова пошли во двор. Только вышли на улицу, на них набросился злой пёс. От испуга они разлетелись в разные стороны. Тина и Хин успели забежать домой, только Отвит был слишком напуган и не смог даже пошевелиться. А злой соседский пёс рычал и бежал в сторону маленького котёнка. Друзья, которые успели забежать домой, оглянулись и поняли, что Отвита рядом не было. Тина и Хин пошли спасать своего друга. Подбежали к напуганному котёнку, схватили его и побежали домой. Закрыли дверь на замок.

Котята были настоящими и храбрыми друзьями.

Амир ФАТИХОВ,
Муслюмовская гимназия, 1 класс.



Карлар ява

Уңыш биреп, эшен тәмам иткәч,
Җир җыенды татлы йокыга.
Сулыклар да бозга әйләнделәр,
Чыдамыйча кышкы салкынга.
Бөтерелеп карлар зәңгәр күктә
Гүя кышкы вальс әйләнә.

Йомшак юрган ябынып дөнья шулай
Әзерләнә кебек бәйрәмгә.
Яусын җиргә карлар, тәңкә карлар,
Алып килсен Яңа елларны.
Бары аклык-сафлык биләп алсын,
Шатлык-бәхет бассын дөньяны.

Ләйсән ЗЫЯДИЕВА,
Олы Кайбыч, 3 нче сыйныф.


ЯҢА БӘЙГЕ!



КАДЕРЛЕ ДУСТЫМ!

СИҢА КЫЗЫКЛЫ БИРЕМНӘР ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ. МАКСАТ – АЛАРНЫ ИГЪТИБАР БЕЛӘН УКЫП ЧЫГУ ҺӘМ ҖАВАПЛАРЫН ТАБУ. ҖАВАПЛАРЫҢНЫ 2017 ЕЛНЫҢ 1 МАЕНА КАДӘР РЕДАКЦИЯГӘ ЯКИ ЭЛЕКТРОН АДРЕСКА ЮЛЛА. ИҢ ОРИГИНАЛЬ, ТУЛЫ, КЫЗЫКЛЫ ҖАВАП БИРҮЧЕГӘ – БҮЛӘК! ШУЛАЙ УК ҺӘРБЕР КАТНАШУЧЫГА «САЛАВАТ КҮПЕРЕ» МАКТАУ ХАТЛАРЫН ӘЗЕРЛӘП КУЯЧАК.

ХАТТА ИСЕМ-ФАМИЛИЯ, ЯШЬ, АДРЕС, ТЕЛЕФОН НОМЕРЫҢНЫ ЯЗАРГА ҺӘМ 2017 ЕЛНЫҢ ИКЕНЧЕ ЯРТЫЕЛЛЫГЫНА КВИТАНЦИЯ КҮЧЕРМӘСЕН БЕРКЕТЕРГӘ ОНЫТМА! ДУСТЫМ, ҖАВАП БИРЕР АЛДЫННАН ӘҮВӘЛ БИК КАТЫ БАШЫҢНЫ ЭШЛӘТ, УЙЛА, ЯМЕ?



АЕРЫЛМАС ДУСЛАР



Элек заманнарда ук шагыйрьләр бик дус яшәгән. Мәсәлән, Александр Пушкин Тукайның шигырьләрен яттан сөйләргә яраткан. Тукай исә, үз чиратында, Пушкинга ияреп яңа шигырьләр язган, аны үзенең остазы дип атаган. Алар бик еш электрон хатлар алышканнар. Пушкин Тукайның фотоларын үзенең инстаграмына куеп барган. Ә Тукай һәр яңа шигырен «WhatsApp» аша дустына җибәрә торган булган.

Бүгенге көндә шулай аралышып йөргән нинди татар һәм рус шагыйрьләрен беләсең?



ИГЕЗӘКЛӘР



Ике бик матур кар бөртеге әйләнә-әйләнә һавада уйный, ди. Алар янына тагын өчесе килеп кушылган. Болар бишәү булганнар. Кар кызы аптырашта калган: бу кар бөртекләре бер-берсенә бик охшаган, ди. Боларны хәтта микроскоп аша карасаң да, һич тә бер-берсеннән аерып булмый икән. Ләкин шулай да Кар кызы хәйләсен тапкан. Ничек микән?



ЯРЫШ



Мияубикә кушаматлы мәче белән Чик-чи дигән тычкан йөз метрга йөгерүдә ярышырга уйлаган. Җиңүчегә бүләккә бер чүлмәк каймак һәм Акбай башы чаклы сыр әзерләп куелган. Акбай үзе хөкем итүче булган.

Ул «старт» диюгә, ярыш башланган.

Мияубикә бик каты чаба икән. Шуңа күрә тычканны ул бик тиз узып киткән. Ләкин Мияубикәнең юлында бер чиләк тәмле сөт очраган. Ул ялгыш шуңа сөрлеккән дә бераз арттарак калган! Чик-чи көлә-көлә узып киткән. Тик аның юлына да бер кисәк бик тәмле сыр күтәреп килүче икенче тычкан баласы очраган. Ул бик каты чабып килгән мәчене күргәч, куркуыннан сөртенеп егылган, ә Чик-чи аңа килеп бәрелгән, ди. Шулай итеп, Мияубикә аны тагын узып киткән.

Чик-чи хурлыгыннан елый башлаган. Ул шул хәтле каты елаган ки, аның күз яшеннән юлда нәни күл хасил булган. Мияубикә ялгыш шул күлгә кереп чумган. Моны Чик-чи тагын узып киткән бит инде. Мәче бик хурланган, ачуыннан тычкан баласын тотып кыйнамакчы булган. Ләкин хөкемдар Акбай аңа: «Алай ярамый»! – дип бармак күрсәткән.



Финишка боларның кайсы беренче булып килеп җиткән?



БЫЕЛ КЫШ БАБАЙ КИЛМИ







Тиздән Яңа ел җитә. Ләкин Кыш бабай бәйрәмгә килергә ашыкмый, ди. Чөнки ул яши торган Африка илендә маймыллар да Яңа ел бәйрәме үткәрә икән. Алар Кыш бабайны үзләренә кунакка алданрак чакырган.


Ничек уйлыйсың, Кыш бабай быел безгә Яңа ел бәйрәменә килергә соңга калмасмы?

КАР КЫЗЫ КЫШ БАБАЙ КАПЧЫГЫНА БҮЛӘКЛӘР ТУТЫРА. АҢА БҮЛӘКЛӘРНЕ ДӨРЕС ТАРТМАЛАРГА САЛЫРГА ЯРДӘМ ИТ. КАЙСЫ УЕНЧЫК ТАРТМАСЫЗ КАЛДЫ?














Җаваплар salavatkupere.com сайтында.


КЫШ БАБАЙ ҺӘМ КАР КЫЗЫ РӘСЕМЕН ЯСАП БЕТЕР.





МИСАЛЛАРНЫ ДӨРЕС ИТЕП ЧИШ.









ЯҢА ЕЛ ТЫЛСЫМЫ

Мәктәпкә әзерлек төркеме өчен әдәби-музыкаль кичә

КАТНАШАЛАР: АЛЫП БАРУЧЫ, ПАТША, КЫШ БАБАЙ, КАР КЫЗЫ, ТЫЧКАННАР ПАТШАБИКӘСЕ, АЛЛАДИН, ТЫЧКАННАР, КАР БӨРТЕКЛӘРЕ, СОЛДАТЛАР, ШӘРЫК КЫЗЛАРЫ.

Зал бәйрәмчә бизәлә. Зал уртасында – чыршы. Чыршы алдында патша тәхете тора. Балалар залда ярымтүгәрәк ясап басып торалар. Тантаналы көй яңгырый.

ПАТША. Бүген безнең патшалыкта бал-маскарад булачак! Барыгыз да балга карнавал киемнәре киеп килегез! Бәйрәмгә Кыш бабай һәм Кар кызы килүе дә көтелә.

Балалар яңа ел турында шигырьләр сөйли, җырлар башкара.

АЛЫП БАРУЧЫ. Балалар, бәйрәмгә Кыш бабай һәм Кар кызының да килә дигән иде бит патша. Нишләптер күренмиләр. Әллә чакырып карыйкмы үзләрен?

БАЛАЛАР. Кыш бабай! Кар кызы!

Матур көй уйный. Кыш бабай белән Кар кызы керә.

КЫШ БАБАЙ.

Күрәм мине көткәнсез,
Чыршыны бизәгәнсез.
Матур итеп киенеп,
Бәйрәмгә дип килгәнсез.

ПАТША. Менә, дуслар, Кыш бабай белән Кар кызы да килеп җитте. Кыш бабай, син безгә бер тылсымлы әкият сөйләсәң иде...

КЫШ БАБАЙ. Хәзер мин сезгә иң яраткан әкиятемне сөйлим.

Залда ут сүнә, чыршыдагы утлар яна. Түшәмгә эленгән көзгеле шар әйләнә башлый. Кар кызы һәм кар бөртекләре биюе башкарыла. Бию тәмамлануга, караңгыда кинәт кенә тавыш-гауга ишетелә. Кыш бабай белән Кар кызы сиздерми генә чыгып китә.

ПАТША. Ай-ай-ай, нәрсә бу? Кем ул этешә-төртешә? Ай!

Ут яна, тәхеттә тычканнар патшабикәсе утыра. Патша куркып кына чыршы артыннан карап тора. Тычканнар патшабикәсе уенчык Кыш бабайны җепкә элеп, аны бармагына чорнап, уйнап утыра.

ТЫЧКАННАР ПАТШАБИКӘСЕ. Хәзер монда мин хуҗа! Үзләре күңел ача, бәйрәм итә, ә менә мине чакырырга онытканнар. Ярый, хәзер инде барысы да мин теләгәнчә булыр. *Юри генә кызганган булып, уенчык Кыш бабайга карап куя.*

ПАТША. *Чыршы артыннан чыга.* Балалар, нәрсә соң бу? Ул безнең Кыш бабабызны сихерләгән, аны уенчыкка әйләндергән бит. Кар кызы да юкка чыккан.

ТЫЧКАННАР ПАТШАБИКӘСЕ. Бу матур Кыш бабагыз белән чыршыгызны бизи аласыз. *Уенчыкны патшага суза.*

ПАТША. *Уенчыкка карап.* Ай-яй, бичара Кыш бабай! Ай, мескен Кар кызы! Берәр нәрсә уйлап табарга кирәк. Без бит бердәм, без бит күп. Бу явыз, мәкерле патшабикәне җиңеп чыга алмабызмыни?!

ТЫЧКАННАР ПАТШАБИКӘСЕ. Һай, куркыттыгыз! Миңа каршы чыгарга көчегез җитмәячәк. Минем гаскәремне күрсәгез! Тычканнар, алга, җиңәргә! Бәйрәмне бозарга, кимерергә, җимерергә!

Тычканнар белән тычканнар патшабикәсе биюе башкарыла.

ПАТША. Безнең патшалыгыбызда төрле әкият геройлары яши бит әле. Бу тычканнарны җиңә алучыны таба алмабызмыни?

Солдатларым минем,
Чыгыгыз тизрәк.
Явыз тычканнарны
Куарга кирәк.

ТЫЧКАННАР ПАТШАБИКӘСЕ. Күрәм, күрәм, солдатларыгыз батыр да, көчле дә икән. Ләкин минекеләрне уздыра алырлар микән?

ПАТША. Алайса, әйдә, ярыш уздырыйк.

«Аркан тартыш» уены. Тычканнар һәм солдатлар командасы аркан тартыша. Тычканнар җиңелә.

ТЫЧКАННАР ПАТШАБИКӘСЕ. Ярый, булдырдыгыз! Җиңеп чыктыгыз. Ләкин мин моны болай гына калдырмаячакмын. *Йөгереп китә һәм кереп кача.*

ПАТША. Без синнән курыкмыйбыз! Тик ничек кенә Кыш бабай белән Кар кызын коткарырга соң? Аларны кире үз хәлләренә ничек кайтарырга? *Чыршыда утлар җемелди.* Карагыз әле, чыршы нидер әйтергә тели түгелме? Әнә бит, чыршыда Алладинның тылсымлы лампасы эленеп тора икән! *Патша уенчык лампаны сыпыра, ут сүнә. «Алладин» мультфильмыннан көй яңгырый. Көй туктагач, ут яна. Мендәрләр өстендә Алладин утыра.* Хөрмәтле Алладин! Безнең зур борчуыбыз бар. Безнең Яңа ел бәйрәме барганда явыз тычканнар патшабикәсе Кыш бабабызны уенчыкка әйләндереп, аны чыршыга элеп куйды.

АЛЛАДИН. Мин сезгә ничек ярдәм итә алам?

ПАТША. Безгә синең тылсымлы лампаң кирәк.

АЛЛАДИН. Ярар, мин сезгә тылсымлы лампамны бирергә риза. Ләкин моның өчен балалар миңа үзләренең нәрсәгә оста булуларын күрсәтсеннәр.

Балалар шигырьләр сөйли, җырлар җырлый. Алладин лампаны патшага бирә.

ПАТША. Рәхмәт, Алладин! *Лампаны сыпыра.*

Залда ут сүнә. Тылсымлы көй яңгырый. Кыш бабай белән Кар кызы килеп керә.

КЫШ БАБАЙ. Ай, минем кулларым, ай, аякларым! Чыршыда эленеп тору бер дә кызык түгел шул.

КАР КЫЗЫ. Ай, минем дә бөтен җирем оеп бетте.

Шыпырт кына Тычканнар патшабикәсе керә. Кыш бабайның таягын алам дигәндә генә, Кыш бабай аны эләктереп кала.

КЫШ БАБАЙ. Син әле мондамыни? Хәзер мин сиңа бирәм кирәгеңне. *Колагыннан эләктереп ала.* Балалар, бу явызны нишләтәбез? Мин аның үзен дә чыршы уенчыгына әйләндерергә телим.

ТЫЧКАННАР ПАТШАБИКӘСЕ. Юк, кирәкми, мин теләмим! Зинһар өчен гафу итегез! Мин башка беркайчан да явызлыклар эшләмәм.

КЫШ БАБАЙ. Ярар. Елга бер килә торган, балаларның яратып көтеп ала торган бәйрәме – Яңа ел хөрмәтенә генә мин сине гафу итәм.

АЛЫП БАРУЧЫ.

Яшел чыршы тирәсендә
Үткәрәбез зур бәйрәм.
Җырлыйбыз да, биибез дә,
Уйныйбыз әйлән-бәйлән. *Кыш бабай белән Кар кызы балаларга бүләкләр өләшә.*

Зөһрә Нургаян кызы РӘХИМҖАНОВА, Балтач, Кариле.
«Ел тәрбиячесе» бәйгесенең «Иң яхшы автор сценарие» номинациясе җиңүчесе.

Кыш бабай  бүләк өләшә

Аяз ХӘСӘН



Зәңгәр урманга Кыш бабай килгән көннең кичендәге тынлыкны койрыксыз Саескан чәлпәрәмә китерде:

— А-һа-һай! Ишеттегезме әле? Күрдегезме әле?

— Ни булды? Сөйлә инде тизрәк! — дип чыелдады Тычкан.

— Әллә... Әллә урманга аучы килгәнме? — дип калтыранды Тиен.

— Карчыга күренмәгәндер бит? — дип чыркылдады Чыпчык.

Куяннар, куркынып, ялт-йолт карандылар.

— Кыш бабай килә, Суык бабай! — дип кычкырды Саескан.

— Кыш бабай? Бик куркынычмы ул? Усалмы? Тешләмиме? — дип шаулашты җанварлар.

— Хи-хи-хи! — дип көлде Саескан, белдекле кыланып. — Бик шаян ул Кыш бабай. Дәү капчыгына салып, төрле бүләкләр алып килә. Минемише акыллы кошларга бушлай өләшә. Ә сиңа, Чыпчык, бүләк эләкмәячәк, чөнки син аңгыра, тинтәк. Кыяфәтең дә каракныкына охшаган.

— Ә миңа? Миңа? — дип кызыксынды Тиен.

— Сиңа да юк, — дип көлде Саескан. — Синең дә акылың керделе дә чыктылы. Гомумән, сезнең арада акыллы җан иясе юк. Бер Тукран бераз уйларга сәләтле дисәң, анысы да шыр тиле! Бер мин генә акыллы кош, зирәк кош!

— Ә... Ә нәрсә бүләк итәчәк соң сиңа Кыш бабай? — дип сорады Тычкан.

— Маш-шина! — дип күкрәк киерде Саескан.

Шулвакыт урман өстендә: «Кар-р-р!» дигән аваз яңгырады.

Күтәрелеп карасалар, имән башына Ала карга килеп кунган икән.

— Кыш бабай килде! — дип каркылдады ул.

Әйе, зәңгәр урманга Кыш бабай килде. Салкын ак томан булып килде ул, көмеш бәс булып агач ботакларына сарылды. Аннары ак сакаллы, ак тунлы, зур гәүдәле мөлаем бабайга әверелде.

— Йә, җәнлекләрем, кошларым, ничек яшисез? — дип елмайды ул, урман халкына карап.

Кыш бабай, дәү капчыгын чишеп, бүләкләрен чыгара башлады.

Шунда ук әрсез Саескан очып килеп җитте.

— Миңа! Миңа! — дип кычкырды ул, Кыш бабай кулындагы сыбызгыны күргәч. Әмма Кыш бабай сыбызгыны Чыпчыкка бирде.

— Ә миңа? Миңа нәрсә? — дип үрсәләнде Саескан.

Ә Кыш бабай әйтерсең аны күрми дә, уңга-сулга бүләкләр өләшә: Куянга барабан, Тукранга пәке, Тиенгә курчак, Тычканга быргы...

Үзенә өлеш чыкмагач, Саескан, тәмам нәүмиз булып, бер читкә барып кунды. Хурланудан аның күзенә яшь бәреп чыкты.

Шунда нәни Куян түзмәде, кыяр-кыймас кына Кыш бабайның тун җиңенә кагылды:

— Бабай! Бабакай, ә Саесканга нәрсә?

— Ә, Саескан өлешсез калдымыни әле? — дип, хәйләкәр генә елмайды Кыш бабай. — Сезнеңчә ничек, балалар, бүләк тиешме Саесканга?

— Мин аңа үземнең сыбызгыны бирәм, — дип чыркылдады Тычкан.

— Мин барабанымны...

— Мин пәкемне...

Шунда Саескан башын тагын да түбәнрәк иде.

— Йә, ярый, монда аңа да бүләк калган икән әле, — диде Кыш бабай һәм капчыгыннан искиткеч матур зәңгәр шар чыгарып бирде.

Саескан шатлыгыннан нишләргә дә белмәде. Ул үзенең зәңгәр шарын бөтен халык күз алдына — каен ботагына элеп куйды. Урман өстенә сыек зәңгәр яктылык таралды.



«КИКРИКҮК» ЕЛЫ



ДУСЛАР, 2017 ЕЛ – КЫЗЫЛ УТЛЫ ӘТӘЧ ЕЛЫ. УЛ ГАИЛӘНЕ, ӨЙДӘ БЕРГӘ БУЛУНЫ ЯРАТА ИКӘН. ШУҢА ДА ЯҢА ЕЛНЫ ГАИЛӘ ҺӘМ ТУГАННАР БЕЛӘН КАРШЫЛАРГА КИҢӘШ ИТЕЛӘ.
ӘТӘЧНЕҢ КЫЗЫЛ ТӨСЕ 2017 ЕЛНЫҢ УҢЫШЛАРГА БАЙ БУЛУЫ, ҺӘР ЭШНЕҢ ЯХШЫ ТӘМАМЛАНУЫ ТУРЫНДА БЕЛДЕРӘ. ЛӘКИН МОНЫҢ ӨЧЕН ҮЗЕБЕЗГӘ ДӘ ТЫРЫШЫРГА КИРӘК. ӘТӘЧ КУЙГАН МАКСАТЫНДА НЫК ТОРУЧЫ, БЕЛЕМ ТУПЛАРГА, ЯҢАЛЫККА ОМТЫЛУЧЫЛАРГА ГЫНА БУЛЫШАЧАК...



КУЧКАР
21.03-20.04

Иҗади мөмкинлекләрең бар икән, аларны тормышка ашырырга вакыт. Күбрәк аралашырга, дуслашырга тырыш.



ҮГЕЗБОЗАУ
21.04-20.05

Мөһим эшләргә алынырга курыкма, син барысын да булдырачаксың! Бәлки компьютерны өйрәнә башларсың.



ИГЕЗӘКЛӘР
21.05-21.06

Син бар теләкләреңнең дә тиз кабул булуын теләрсең. Ләкин түземле булырга да өйрәнергә кирәк. Шул вакытта барысы да уңай хәл ителер.



КЫСЛА
22.06-23.07

Көтелмәгән сәләтләрең ачылырга мөмкин. Бәлки алар музыка, рәсем яки фән белән бәйле булыр? Ничек булса да, алга таба бар!



АРЫСЛАН
24.07-23.08

Сиңа һәр яңалык кызык булачак. Ләкин кайсын сайлау турында ныклап уйла. Күбрәк сәяхәтләр, төрле маҗаралар файдалы булачак.



КЫЗ
24.08-23.09

Барысын да үзеңчә эшләргә теләвең башкаларга ошап бетмәскә мөмкин. Олылардан үзең белән зурларча сөйләшергә сорасаң, алар синең матур фикерле белүеңне күрәчәк.



ҮЛЧӘҮ
24.09-23.10

Син һәр нәрсә белән кызыксынасың. Шуңа да сорауларыңа җавап эзләүдән туктама. Әти-әниең белән күңел ачу паркына, зоопаркка бара, төрле мавыктыргыч уеннар уйный аласың.



ЧАЯН
24.10-22.11

Тиктормаслыгың, төрле уй-хыялларың ел буена җитәр. Шул ук вакытта төрле түгәрәкләрдә дә уңышларга ирешә аласың. Мәсәлән, инглиз теле яки математика юнәлешен сайларга була.



УКЧЫ
23.11-21.12

Бик актив, аралашучан булырсың. Шуңа да спорт белән шөгыльләнергә тәкъдим ителә. Син һичшиксез уңышка ирешәчәксең!



КӘҖӘМӨГЕЗ
22.12-20.01

Төрле сорауларыңны олыларга бирергә курыкма. Алар сиңа дөньяны танып-белергә ярдәм итәр.



СУКОЯР
21.01-19.02

Син мөстәкыйль булырга омтылырсың. Бу – бик дөрес. Башка мөмкинлекләреңне дә үстерергә тырыш.



БАЛЫК
20.02-20.03

Дусларың тагын да артыр. Чөнки син кунакчыл, аралашучан һәм күп беләсең. Бу сыйфатларың яшьтәшләреңә дә ошар.

ЯҢА ЕЛ ХУҖАСЫ

Битлекне һәм күз урыннарын пунктир буенча кисеп ал, ян-ягына резин тасма беркет. Яңа ел бәйрәменә кию өчен битлек әзер!



УКТАЛЫ ДА ЧУКТАЛЫ,
МУЕНЫ ЯШЕЛ НУКТАЛЫ,
ТҮБӘСЕНДӘ ТАРАГЫ,
КОЙРЫГЫНДА УРАГЫ,
ТӘПИЕНДӘ СӘНӘГЕ,
ШУЛ НИ БУЛЫР, ЙӘ ӘЛЕ?




Язылһәм телевизор от!

1 Языл
30.12.2016 кадәр «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең кимендә 3 басмасына языл *(акциядә катнаша торган басмалар белән tatmedia.ru сайтында таныша аласың)*

2 Җибәр
язылу квитанцияләренең күчермәсен «Акция» билгесе белән түбәндәге адреска җибәр *(телефон номерыңны күрсәтергә онытма)*: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 яки podpiska@tatmedia.ru

3 От
Телевизор, фотоаппарат һ.б. бүләкләр!









Акцияне үткәрү вакыты: 20.10.2016 - 20.03.2017

Акция турында тулырак – tatmedia.ru сайтында
Оештыручысы – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте
Белешмәләр өчен телефон: (843) 222-09-84 өстәмә номер - 1261

16+
Реклама